*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Трагедия жанры турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. Мисаллар китерегез. (6 балл)**

**2. Фоторәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча эшләнгән? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (6 балл)**



**3. Алтын Урда чоры әдәбияты кайсы гасырны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (2 балл)**

а) XIII йөзнең урталарыннан алып XV гасырның ахырлары

ә) XV гасыр урталарыннан башлап XVI гасырлар

б) XV гасыр урталарыннан XVII гасыр урталарына кадәр

**4. XIX гасыр әдәбияты драматургын билгеләгез. (2 балл)**

а) Шәриф Хөсәенов

ә) Габдрахман Ильяси

б) Кәрим Тинчурин


**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын языгыз. (6 балл)**

а) «Хәят» ______________________ ____________________

ә) «Ана догасы» ____________________ __________________

б) «Әниемнең ак күлмәге» ____________________ ___________________

**6. Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз. (8 балл)**



1) ____________________________

2) ____________________________

3) ____________________________

**7. Шигырьнең исемен, авторын языгыз. Шигырьне тулысы белән искә төшереп, анда бирелгән хис-кичерешләрне билгеләгез. (5 балл)**

Малай туды безнең. Нинди шатлык!
Икебезгә уртак бәхет таптык.
Сокланабыз аңа исебез китеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Егет үстерәбез туган илгә,

Мондый асыл малай бездә генә,
Тирбәтәбез йоклаганын көтеп,
Өф-өф итеп, өф-өф итеп.

Затлы кием, ефәк аңа гына,
Тәмле-татлы нәрсә тамагына;
Тәпи йөри башлый яңа гына,
Тып-тып итеп, тып-тып итеп.

**8. Бала чагында алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да өйрәтә алмас, диләр. Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**